ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# КӨЗГЕ

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!

ОКТЯБРЬ, 2018 нчы ел

№2 (42)





## Сез иң гүзәл  кеше  икәнсез!

***Кадерле укытучыларыбыз!***
***Бәйрәмегез котлы булсын!***
***Сәламәт булыгыз¸күңелегез***
***бер дә картаймасын!***
Халык күңелендә Сезгә дигән
Меңәрләгән чәчәк бәйләме
Әгәр аны алдыгызга куйсак
Булыр иде таулар кадәрле…
Кояшны да бүләк итәр идек
Кояш биек, ә без кечкенә
Чәчәктән дә матур, назлы бүләк
Тапмадык без бүген һич кенә.

Укытучы! Ә кем сон ул? Укытучы - сабыйны кулыннан тотып белем дөньясына алып керүче , барлык һөнәрләргә юл ачучы кеше ул. Киләчәктә нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә уңышларыбызның башында укытучыбыз тора.!






Бу санда:


| | |
|---|---|
| Сез иң гүзәл кеше икәнсез! | 1 |
| Мәктәп тор-мышы. Үзидарә көне | 2 |
| Мәктәбебезгә нур иңгән, чөнки өлкәннәр | 3 |
| Өлкәннәрне котлау | 4 |
| Уңыш бәйрәме | 5 |
| Мәктәп тор-мышы. | 6 |
| Укучылар иҗаты | 7 |
| Башваткы-члар | 8 |
| Котлыйбыз | 9 |

# МӘКТӘП ТОРМЫШЫ.






## Үзидарә көне.

5 октябрь көнне мәктәптә Укытучылар көненә багышлап үзидарә көне игълан ителде. Һөнәри бәйрәмнәре белән укытучыларны “Фома урта мәктәбе” балалар оешмасы котлады.

“Без атна буе, мәш килеп, укытучы булырга әзерләндек. Мәктәптә бүген–без хуҗа! Остазларыбыз яңа коллегаларын күз кырые белән генә күзәтәләр, серле елмаялар...

Укытучылар көне уңаеннан Сезгә ихлас теләкләребезне җиткерәбез! "Укытучы" сүзе нинди генә телдә яңгыраса да, һәрвакыт тирән ихтирам һәм хөрмәт хисләре белән әйтелә. Укытучы-һәрберебезнең йөрәгендә ата-аналарыбыз кебек бер дәрәҗәдә якын һәм кадерле кеше. Укытучы гомер-гомергә халыкка хезмәт итүдә, тирән гражданлык һәм ватанпәрвәрлек, белемгә омтылу хисләре, мәдәниятле шәхес тәрбияләү белән чагылдырыла. Укытучы булу - ул Ходайдан бирелгән сәләт. Бары тик зур талантка ия кеше генә яшьләргә кешелек тарафыннан тупланган тормыш тәҗрибәсен, әхлакый кыйммәтләрне һәм белемне түкми-чәчми җиткерә ала, тәрбияләргә алына. Хезмәт сөючәнлек, иҗади якын килү, мәрхәмәтлелек һәм балаларга карата мәхәббәт - әлеге күркәм сыйфатларны Укытучыда без көн саен күрәбез.

Укучыларыгызның һәрберсенә җан җылысын биреп белем өләшүегез өчен сезгә чиксез зур рәхмәт!

Сезнең тырышлыгыгыз, талантыгыз, йокысыз үткәргән төннәрегез шатлык булып кайтсын. Бәхет, җан тынычлыгы телибез! Бәйрәм белән, хөрмәтле укытучыларыбыз!”.

Зарипова Зилә

## РӘХМӘТ СИҢА, УКЫТУЧЫМ!

Бу дөньяда миңа ике кеше –
Укытучым белән әнием –
Бик тә якын, бик тә гүзәл,
Аларга сон тагын ни дим?

5 октябрь көнне гаделлек, зирәклек кебек күркәм сыйфатларны үзләренә туплаган һөнәр ияләре – укытучылар көне. Бәйрәм көне уңаеннан мәктәптә төрле күңелле чаралар үтте. Укучыларыбыз мәктәп ишегеннән кергәндә үк, укытучыларыбызны котлады, сюрпризлар әзерләде. Шулай ук Мәктәп үзидарәсе оешмасы “Котлау линейкасы” оештырды.Һәр сыйныфта бәйрәм тантанасы рухы күзәтелде. Шарлар, төсле акбурлардлар белән язылган җылы сүзләр, чәчәкләр... Барысы да ераткан укытучылар хөрмәтенә. Мөгаллимнәребез хөрмәтенә укучылар “Рәхмәтемнең иң олысы сиңа, Укытучым” исемле әдәби музыкаль кичә оештырдылар. Бәйрәм матур җырлар, шигырьләр, биюләр һәм котлаулар белән үрелеп барды.

Хисматов Рәсим




## Өлкәннәр көне.

Ел саен 1 октябрьдә бөтен илебез Халыкара өлкәннәр көнен билгеләп үтә. Бу көндә мәктәбебездә эшләп, хәзерге вакытта лаеклы ялда булган хезмәткәрләр, өлкән яшьтәге әби-бабайлар кичәнең кадерле кунаклары булдылар.

Өлкәннәргә аеруча зур игътибар бирү көнендә алтынсу көз айлары һәм гомер көзләренә керү бераз моңсулык алып килсә дә, икенче яктан тормышның шатлыкларына сөенеп яшәр чак икәнен дә аңлыйсың. Лаеклы ялга чыккан әби-бабайлар, балалар, оныклар бәхетенә куанып, изге эшләр башкарып яшәр чак килеп җиткәнен искә төшерделәр.

Халыкара өлкәннәр көнендә генә түгел, ел әйләнәсендә игътибар һәм кайгыртучанлык белән ветераннарыбызны җылыту, аларга рухи таяныч булу – безнең бурычыбыз.

Гумерова Ләйсән



## Мәктәбебезгә нур иңгән,чөнки өлкәннәр килгән.

Хәер, әлеге мөхтәрәм кешеләребез һәр көн саен хөрмәткә лаеклы булсалар да, Берләшкән Милләтләр оешмасының Генераль Ассамблеясе карары нигезендә 1 нче октябрь, алар өчен махсус - Өлкәннәр көне дип билгеләнгән. Шул уңайдан мәктәбебездә алдан төзелгән план нигезендә төрле чаралар үткәрелде. Октябрьнең 1нче көне мәктәбебездә ел саен олы бәйрәмгә әйләнә. Гомер буе бар тырышлыкларын балаларга белем бирүгә багышлаган мөгаллимнәр, мәктәптә техник хезмәткәр, пешекче булып эшләгән өлкәннәр бу көнне безнең иң кадерле һәм көтелгән кунакларыбыз була. Быел да өлкәннәрне котларга өйләренә “Яшь исспекторлар хәрәкәте» «Россия укучылары хәрәкәте» «Җиңү волонтерлары” оешмасы әгъзалары бардылар һәм котлап бәйрәмгә чакырып кайттылар. Сыйныфларда тәрбия сәгатьләре уздырылды. Әлеге бәйрәм дөньяның бөтен кыйтгаларында билгеләп үтелә. Тәрбия сәгате барышында укучылар әлеге истәлекле көннең тарихы белән таныштылар. Картлык чорының үз шатлыклары хакында мәгълүмат тупладылар. Өлкән яшьтә дә актив булып калу өчен нинди таләпләр үтәргә кирәклеген ачыкладылар . Ә инде бәйрәм көнне Ммктәптә “Яшәгез сез мәңге яшь булып, туган йортыгызда ямь булып” дип исемләнгән чыгышыбыз алар хөрмәтенә багышланды. Кунакларыбыз укучыларның һәр чыгышын яратып карады, озаклап алкышлады. Алар безгә шушы җылы һәм матур мәктәпләрдә белем алуыбызның кадерен белергә, мәктәптә уздырган һәр көнне файдалы итеп уздырырга киңәш иттеләр. Шуңадыр, һәр чыгыш исемдә калды. Безнең концерт бик матур иде, өлкәннәребез моңа бик лаек! Бәйрәм чәй табыны янында дәвам итте.

Хайруллина Әдилә.


# Өлкәннәрне котлау күренешләреннән фоторепортаж



Фахриева Гөлфия Якуп кызы 9 сыйныф “Яшь инспекторлар хәрәкәте» оешмасы белән озак еллар укытучы хезмәтен башкарган Хафизова Нәгыймә Нурлыгаян кызын бәйрәм белән котладылар.



Аглиуллина Гөлүсә Дамир кызы Биккол авылында укучылар белән Вафин Дамир Бәхтегәрәй улын һәм Вафина Роза Суфиян кызын бәйрәм белән котладылар.





Сафиуллина Резидә Дамир кызы 6 нчы сыйныф укучылары белән озак еллар пешекче хезмәтен башкарган Ибрагимова Наилә Сәлих кызын һәм Закирова Сакина Туктар кызын Өлкәннәр көне уңаеннан бәйрәм белән котладылар.



Садртдинова Рузилә Нурислам кызы 8 сыйныфлар белән мәктәптә җитәкче булып эшләгән Каримов Сәлим Мирзаҗан улын һәм бакчада үзенең хезмәтен яратып башкарган Каримова Асия Мотыгулла кызын бәйрәм белән котладылар.

Хөрмәтле өлкәннәребез!
Кайгыртып гел безнең кайгыларны
Безнең янәшәдә яшисез.
Ходай Сезгә озын гомер бирсен,
Рәхмәт Сезгә, олы кеше Сез!

# Уңыш бәйрәме!

Шатлыклар – күңелебездә

Ал кояш – күгебездә!

Рәхәтләнеп бәйрәм иттек –

Алтын Көз килде безгә!

Быел көз бик матур килде. Әкияттәгедәй матур булды,”Алтын көз”дигән исемне тулысынча аклады. Матур көзнең көннәрен озынайтырга теләгәндәй, Көзбикә , ашыкмыйча гына,безнең мәктәпкә дә килеп җитте .Бу көнебез барыбыз өчен дә бик истәлекле булды. Мәктәптә барлык укучылар көләч йөзлеләр иде. Бәйрәмебезнең беренче өлеше башлангыч сыйныфлар өчен «Без көзләрне яратабыз» дип аталган бәйрәм узды. Һәр сыйныф үзенчәлекле чыгыш әзерләгән. Шигырьләр сөйләделәр,җырладылар ,биеделәр., төрле уеннар оештырылды. Балалар рәхәтләнеп ял иттеләр, көч сынаштылар. Икенче өлеше 5,6,7 сыйныфлар өчен бик матур «Кабак» бәйрәме уздырылды. Укучылар төрле әкиятләрне сәхнәләштереп курсәттеләр.

Яфракларны да таныдылар, табышмакларга да җавап бирделәр. Гомумән бәйрәм бик күңелле үтте һәм чәй табыны артында дәвам итте.

8-11 сыйныфлар өчен “Көзге бал”кичәсе булып үтте. Кичәне 9 нчы сыйныф укучылары алып барды. Бәйрәмдә 8.10,11 нчы сыйныф укучылары катнашты. Төрле уеннарда, ярышларда көч сынашып, һәр сыйныф укучылары үзләренең сәләтләрен, осталыкларын күрсәттеләр. Бәйрәмнең концерт номерлары белән үрелеп баруы, аңа тагын да ямь өстәде. Күптән көтеп алынган бу кичә һәр укучының күңелендә матур истәлек булып сакланыр .

Кәбирова Дилбәр









# Мәктәп тормышы

## Юлда сак булыгыз!



«Светофор» кружогына йөрүче 4 сыйныф укучылары «Яшь инспекторлар хәрәкәте республика күләмендә оештырылган акциядә актив катнашты.



## Җиңү волонтерлары.

Республикабызда инде берничә ел “Волонтеры Побды” проекты эшләп килә. 10 сыйныфтан 4 укучы, 8 сыйныфтан 1 укучы да бу проектка кушылды.Сугыш ветераннарына,тыл ветераннарына,өлкәннәргә булышу, ярдәм итү максатыннан оештырылган проект бу. Өлкәннәр үнкөнлегендә бу проект уз эшен башлап җибәрде.Алар сугыш ветераны Шагапов Сәйфетдиннең хатыны Шагапова Минҗһан әби белән очраштылар.



## Парламент дәресләре


17 октябрь көнне Парламент дәресе булып үтте.Дәрестә 5-6 сыйныф укучыларына депутат Гумерова Рания чыгыш ясады. Ул укучыларны дәүләт думасы, депутат,парламент төшенчәләре белән таныштырды.



## Ел лидеры конкурсы

Республика күләмендә үткән «Ел лидеры» конкурсына безнең мәктәптән Гумерова Ләйсән үтте. Һәм мәктәбебезне яклап блоклап үткәрелгән конкурста катнашып грамота алып кайтты. Үзенең проектын уңышлы яклап грамота алып кайтты. «Эле икенче елга да барам һәм җиңеп кайтам , диде Ләйсән.

# Укучылар иҗаты



Көз җиттеме, җир өстенә
Алтын яфрак җәелә.
Карап туеп булмый һич тә
Бу фасылның яменә.




Октябрь

Көз фасылының икенче ае - октябрь башланды. Халык телендә елның бу мизгелен кара көз дип тә йөртәләр, чөнки табигать инде үзендәге яшеллекне тәмам җуйды диярлек. Кырларда игеннәр урылды. Туңга сөрелгән басу өсләре дә күптән каралып калдылар. Урамнарны, юлларны көзге пычрак каплады.

Житмәсә, әле октябрь –яктылыкка да шактый ярлы ай.

Ләкин без моңсуланып утырмыйбыз.Чөнки октябрь башында иң матур бәйрәмнәрне билгеләп үтәбез. Болар безнең өчен кадерле булган өлкәннәребез көне һәм хөрмәтле укытучыларыбыз көне.








Хисматова Зәринә, 7 класс

# Башваткычлар

***Кроссвордны чишкәч, тезмә сүз барлыкка килә. Дусларым! Нинди сүз икән ул?***

*1.Табигатьне, яшәешне өйрәнә торган фән.*
*2.Мәктәп - ... чишмәсе.*
*3.Татар теле һәм әдәбияты укытучысы исеме.*
*4.“Матур, чибәр, гүзәл” – нинди сүзләр?*
*5.Саба районы авылы.*
*6.Явым-төшем.*
*7.Чәчәк һәм кыз исеме.*
*8.Укучының ин беренче кулына алган китабы.*
*9.Габдулла Тукай шигыре.*
*10.Мәктәп белән идарә итүче.*
*11.Татарстанның гимн сүзләрен язучының исеме.*
*12.Мәктәп кирәк-ярагы.*




## Мәктәп тормышыннан кызыклы хәлләр...

-Укучылар, ял вакытында нинди яхшылыклар эшләдегез?
-Апа, мин ике яхшылык эшләдем.
-Нинди яхшылыклар инде ул?
-Әбигә кунакка килдем, әбием бик шатланды.
-Икенче шатлык нәрсә? Әбиеңә булышкансыңдыр инде, мөгаен?
-Әбидән киттем. Әбием кайтканга караганда күбрәк шатланды…

-Улым, көндәлегеңне бир әле.
-Әни, мин аны Маратка биреп тордым.
-Ник?
-Әти-әнисен куркытырга.
-???

География дәресендә.
-Укучылар, Англиянең башкаласы- Лондон. Ул күп вакыт томан белән капланган була. Аяз, әйдә, картадан күрсәт әле.
-Лондон, Лондон, Лондон...
-Табып булмыймы әллә?
-Апа, табып булмый, томан каплаган, ахрысы.

-Айнур, такта янында бик озак торасың бит инде. Фарадей законын кайчан чишәсең?
-Ашыктырмагыз әле. Фарадей бу законын берничә ел уйлагач кына ача алган.

# Котлыйбыз!





Октябрь аенда туучы укучыларыбыз:

Маняпов Ильнар,Галиуллина Әдилә, Мөхәммәтшин Рәзил, Гайсин Марсель, Гайсина Вероника, Ситдиков Илнур, Галиуллин Илнар!

Сезне барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар , исәнлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!




Хөрмәтле Әнисә Ялалетдин кызы,

Гөлфия Якуп кызы!

Сезне чын күңелебездән туган көнебелән тәбрик итәбез.

Сезгә шушы бәйрәмегездә теләкләрнең иң изгесен, иң сафын юллыйбыз. Җаныгыздагы йолдызлар балкышын сүндермичә, күңелегездәге яшәүнең алкышын киметмичә, сәламәтлек дәрьясында коеныл яшәвегезне телибез.

Котлы булсын туган көнең,
Матур булып атсын таңнарың.
Рәхәт яшә, игелеге кайтсын
Сез сыйлаган һәрбер баланың.

**“ К Ө З Г Е ”Директор:** Сафиуллин Халим Салих улы ***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды. (423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18) Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011 Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга. Тиражы чикләнмәгән. **Баш мөхәррир**: Садртдинова Рузилә Нурислам кызы **Урынбасары**: Гумерова Ләйсән : **Корректор**: Сафиуллина Резидә Дамир кызы . **Редколлегия:** Зарипова Зилә, Кәбирова Дилбәр, Хисматова Зәринә